ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

# КАРАР

«03» ноябрь 2023 ел № 930

**«Бинаны торак бина, торак бинаны яшәү өчен яраксыз, күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм җимерелергә яисә реконструкцияләнергә тиеш дип тану буенча район ведомствоара комиссиясе төзү турында» Арча муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 18 декабрендәге 1035 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында (2023 елның 10 октябрендәге 859 номерлы үзгәреш белән)**

"Бинаны торак бина, торак бинаны яшәү өчен яраксыз, күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм җимерелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле, торак йортны бакча йорты, бакча йортын торак йорт дип тану турында нигезләмә" Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 28 гыйнварындагы 47 номерлы карары нигезендә Арча муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.«Бинаны торак бина, торак бинаны яшәү өчен яраксыз, күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм җимерелергә яисә реконструкцияләнергә тиеш дип тану буенча район ведомствоара комиссиясе төзү турында» Арча муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 18 декабрендәге 1035 номерлы карарына (2023 елның 10 октябрендәге 859 номерлы үзгәреш белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Бинаны торак бина, торак бинаны яшәү өчен яраксыз, күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм җимерелергә яисә реконструкцияләнергә тиеш дип тану буенча район ведомствоара комиссиясе составын әлеге карарга кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә ( http://arsk.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Р. М. Гатиятов

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
ИНН 1609009516

Башкарма комитетның
03.11.2023 г. ел, № 930
карарына кушымта

**Бинаны торак бина, торак бинаны яшәү өчен яраксыз, күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм җимерелергә яисә реконструкцияләнергә тиеш дип тану буенча район ведомствоара комиссиясе составы**

| | |
|---|---|
| Гатиятов Р. М. | - Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, комиссия рәисе; |
| Хәсәнов И.М. | - Арча муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы, комиссия секретаре. |
| ***Комиссия әгъзалары:*** | |
| Касыймов Р.Ф. | - Арча шәһәре башкарма комитеты җитәкчесе, комиссия рәисе урынбасары (килешү буенча); |
| Әгълиев И.К. | - «Арча муниципаль районының идарәче компаниясе» ЖЧЖ директоры (килешү буенча); |
| Гатиятова Е.Н. | - «Татарстан Республикасының техник инвентаризация бюросы» АҖ бүлекчәсе җитәкчесе (килешү буенча); |
| Арефьева Е.Н. | - Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең үзәк инспекторлык бүлеге башлыгы (килешү буенча); |
| Салкова Э.В. | - Арча, Биектау, Әтнә, Балтач районнары буенча баш дәүләт санитария табибы (килешү буенча). |

Искәрмә: Комиссия компетенциясенә кертелгән мәсьәләләрне хәл иткәндә, комиссия составына торак бина урнашкан территориядәге авыл җирлекләре башлыклары кертелә.